Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423643, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы,
Монашево авылы,
Мэктэб урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.11.2023 г. № 4

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 30 ноябре 17.00 сәг. Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2 Җыенны уздыру урыны итеп Илнәт авылы Клуб урамы 6 йорт адресы буенча урнашкан Илнәт авылы клубын билгеләргә

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

« «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 -2 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, ә карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән 500 сум күләмендә билгеләргә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

1.Үзәк урамга вак таш салу;

2. Янган урам яктырткычларын алыштыру;

3.Карны чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Монашево авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов